Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы

# КАРАР

15 июнь 2022 ел №18

Түбән Үрәс Советының 2018 елның 27 апрелдәге 6 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексы нигезендә, Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Түбән Үрәс Советы карар бирде:

1. Түбән Үрәс Советының 2018 елның 27 апрелдәге 6 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Түбән Үрәс авыл җирлеге Советның 2018 елның 29 октябрендәге 29 номерлы, 2019 елның 16 маендагы 8 номерлы, 2020 елның 23 мартындагы 8 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 4 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1. пунктында:

а) 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын (пеодданнствосын) туктату турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы (пеодданнствосы) туктатылганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча язмача хәбәр итәргә;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктчасын өстәргә:

«9.1. яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) чит ил гражданлыгы (подданство) алу турында яисә гражданның яшәү төре алуы яки чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алуы турында муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма чит ил гражданлыгы (подданство) алганнан яисә гражданның яшәү төре алган яки чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алган көненнән 5 көннән дә соңга калмыйча язмача хәбәр итәргә;

1.2. 8 бүлекнең 1 пунктында:

а) 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының Россия Федерациясе гражданлыгын йә чит ил гражданлыгын (подданство) туктату;»;

б) 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) гражданның чит ил гражданлыгы (подданство) йә яшәү төре яисә чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы башка документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;

1.3. 15 бүлектәге 1 пунктның 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Түбән Үрәс авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: Гордеева Г.И.